Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

4 октябрь, 2023 ел № 5

Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге ТатЦИК ис. авылда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы 2019 елның 08 ноябрендәге 59 номерлы (2021 елның 14 декабрендәге 33 номерлы карар белән расланган үзгәрешләр белән) Шәле авыл җирлеге Советы карары нигезендә **карар чыгарам:**

1. Шәле авыл җирлеге ТатЦИК исемендәге авылда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә:

Гражданнар җыенын 2023 елның 20 октябрендә 13.00 сәгатьтә Совет урамы, 12а йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында уздырырга.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2024 елда ТатЦИК исемендәге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- - гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Шәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге башлыгы И.Р. Әхмәтҗанов